Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенә керүче Какылы-Күл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№12 23 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы-Күл торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлегенә керүче Какылы-Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә алынучылардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору (Какылы-Күл торак пунктында күмү урыннарын төзекләндерүгә (кипкән, корыган агачларны, куакларны кисү, эш һәм килешү буенча хезмәт күрсәтү өчен түләү));
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Какылы-Күл торак пунктында җирлек эчендәге юлларны карап тотуга (юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)?» юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында элергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова